**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.10.2025 № 1181

«2025/2026 елларда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 04 сентябрендәге 986 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше нигезендә Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, баланслы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативын раслау турында» 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары белән (2025 елның 27 маендагы 362 номерлы үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы карары белән ( 21.04.2025 № 253 үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны туклану белән тәэмин итү турында» 16.01.2023 ел, № 21 карары белән расланган өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклануны оештыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә (07.07.2023 ел, № 689, 13.02.2024 № 172, 29.07.2025 № 828), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2025/2026 елларда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 04 сентябрендәге 986 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 1.7 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

- аз керемле гаиләләр;
- 3 һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән аз керемлеләр.

2. Әлеге карар 2025 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин